ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 17 июлендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ статья өстәргә:
«$2^1$ статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:
1) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары – Федераль законда билгеләнгән шартлар нигезендә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә, һәм урта предприятиеләргә кертелгән, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрында алар турында белешмәләр булган хуҗалык итү субъектлары (юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар);
2) гаилә предприятиеләре – түбәндәге шартларның кайсына да булса туры килә торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары:
а) гаилә әгъзалары җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы йә хуҗалык ширкәтенең, хуҗалык партнерлыгының җыелма капиталындагы өлешләрнең барлыгы 50 процентыннан артыграгына яисә акционер җәмгыятьнең тавыш бирү акцияләренең 50 процентыннан артыграгына ия һәм гаилә

әгъзаларының берсе мондый юридик затның бердәнбер башкарма органы йә хуҗалык җәмгыятенең директорлар советы (күзәтчелек советы) рәисе булып тора;

б) җитештерү кооперативы, кулланучылар кооперативы, крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзаларының кимендә 50 проценты бер гаилә әгъзалары булып тора йә крестьян (фермер) хуҗалыгы бер граждан тарафыннан төзелгәндә – әлеге эш урыны төп эш урыны булган крестьян (фермер) хуҗалыгының кимендә бер хезмәткәре крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгының гаилә әгъзасы булып тора;

в) индивидуаль эшкуарда төп эш урыны буенча эшли торган хезмәткәрләрнең кимендә 50 проценты индивидуаль эшкуарның гаилә әгъзалары булып тора;

3) гаилә әгъзалары – ир белән хатын, ата-аналар һәм балалар (уллыкка алучылар һәм уллыкка алынучылар), бабайлар, әбиләр һәм оныклар, бертуган һәм бертуган булмаган (атасы яисә анасы уртак булган) абый-энеләр һәм апа-сеңелләр.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $22^1$ статья өстәргә:

«$22^1$ статья. **Гаилә предприятиеләре булып торучы Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм**

1. Гаилә предприятиеләре булып торучы һәм Татарстан Республикасы гаилә предприятиеләре реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү Федераль законда, әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка законнарында һәм норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган рәвешләрдә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын гаилә предприятиеләре дип тану тәртибе һәм Татарстан Республикасы гаилә предприятиеләре реестрын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан , Кремль
2025 ел, 23 июль
№ 52-ТРЗ